СОВЕТ СТАРОАЙМАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423739, село Старое Айманово, ул.Новая,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423739, Иске Айман авылы, Яна ур..,5А

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

РЕШЕНИЕ
№ 2

КАРАР
17.01.2019ел

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советынын 2014 ел, 10 ноябрь «Физик затлар мөлкәтенә салым турында "гы 15 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеш), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Иске Айман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» гы 10.11.2014 ел, 15 санлы карарына тубэндэге узгэрешлэрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.1 һәм 3.2 пункт өстәргә::

«3.1.18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк балалары булган физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә. Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, бер өлеше фатир яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән бина яки корылма;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яисә корылмасы;

5) гараж яки машина-урын.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406налы статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.».

2. Актаныш муниципаль районы Аккуз авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 ноябрендәге 29 номерлы«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге «Физик затларның милкенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында " карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авылы, Яңа урам, 5А нчы йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авылы,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл жирлеге Советы рэисе
вазыйфасын вакытлыча башкаручы: А.Ф.Фазуллин